УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.09.2024 Казан шәһәре № 01-05/241-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2024 елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү һәм элек чыгарылган норматив хокукый актны законнар таләпләренә туры китерү максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган нигездә исәпкә алу бүлегенә әлеге боерыкны һәм административ регламент текстын кертелгән үзгәрешләре белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

3. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш.Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 24.09.2024 №01-05/241-пр боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6.1 пунктта:

беренче абзацта «документлар» сүзеннән соң «һәм белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ. Бердәм портал аша гариза биргәндә вәкаләтләр Бердәм порталдан файдаланып төзелгән машинада укыла торган ышанычнамә белән расланырга мөмкин»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«н) индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) (мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча тапшырылырга мөмкин). Мөрәҗәгать итүче тапшырмаган очракта индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) турында белешмәләр, Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан соратып алына;

о) техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (мөрәҗәгать итүче инициативасы белән тапшырылырга мөмкин).».

2.6.1.2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның дүртенче абзацында каралган очракта, бирелгән гариза, аны карау һәм карау нәтиҗәләре турында белешмәләр Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларның тагылмаларын исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертелә яисә җибәрелә»;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар

1) Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсеннән дәүләт пошлинасын түләү факты турында белешмәләр;

2) электрон паспортлар системасыннан техниканың электрон паспортын рәсмиләштерү факты турында белешмәләр;

3) Россия автоиминиятчеләр берлегеннән транспорт чарасы хуҗасының гражданлык җаваплылыгын иминләштерүнең иминият полисы булуы турында белешмәләр;

4) үзйөрешле машина паспортын яисә үзйөрешле машинаның электрон паспортын биргән оешмадан мәҗбүри сертификация Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракта, ярашлылык сертификаты яисә ярашлылык декларациясе булу турында белешмәләр;

3) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булып торган шәхси эшкуар турында өземтә – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән;

6) гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) – Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан яисә Социаль тәэминат итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан;

7) ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр – бердәм нотариат мәгълүмат системасы;

8) мөрәҗәгать итүче тапшырмаган очракта индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) турында белешмәләр, Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып соратып алына;

9) техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, мөрәҗәгать итүче тапшырмаган очракта, тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып соратып алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.2 пунктның 1-9 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне), мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән

таныкланган электрон документлар формасында яки Идарәгә, Идарә бүлегенә кәгазь чыганакта тапшыра ала.»;

3 бүлектә:

3.4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Идарәнең, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм сорала торган документлар (белешмәләр) исемлеге:

1) Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсеннән дәүләт пошлинасын түләү факты турында белешмәләр;

2) техниканың электрон паспортын электрон паспортлар системасыннан рәсмиләштерү факты турында белешмәләр;

3) Россия автоиминиятчеләр берлегеннән транспорт чарасы хуҗасының гражданлык җаваплылыгын иминләштерүнең иминият полисы булуы турында белешмәләр;

4) үзйөрешле машина паспортын яисә үзйөрешле машинаның электрон паспортын биргән оешмадан мәҗбүри сертификация Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракта, ярашлылык сертификаты яисә ярашлылык декларациясе булу турында белешмәләр;

3) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булып торган шәхси эшкуар турында өземтә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән;

6) гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә), Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан яисә Социаль тәэминат итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан;

7) ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр – бердәм нотариат мәгълүмат системасы;

8) мөрәҗәгать итүче тапшырмаган очракта индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) турында белешмәләр, Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып соратып алына;

9) техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, мөрәҗәгать итүче тапшырмаган очракта, тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып соратып алына.

Регламентның әлеге пунктчасында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.6.3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм техника паспорты (техниканың электрон паспортларыннан тыш) техника хуҗасына кайтарыла.»;

3.6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техниканы дәүләт теркәвенә алу:

Россия Федерациясе гражданнарына, шәхси эшкуарларга һәм юридик затларга караган техника буенча Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасына белешмәләр кертеп яисә, алга таба, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын файдаланып, тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – исәпкә алу системалары) җибәреп, «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына белешмәләр кертеп гамәлгә ашырыла;

хуҗасы Россия Федерациясе гражданины булган техника буенча Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан яшәү урыны буенча теркәлмәгән гражданнар өчен – Татарстан Республикасы территориясендә булу урыны адресын, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар өчен – Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урынының адресларын исәпкә алу системаларына кертү яисә җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла;

Юридик затларга караган техника буенча алар урнашкан урын чикләрендә юридик затларның адресын яисә аларның аерымланган бүлекчәләренең урнашкан урыны адресын исәпкә алу системасына кертеп, Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан башкарыла;

Татарстан Республикасында урнашкан дипломатик вәкиллекләргә, консуллык учреждениеләренә, халыкара (дәүләтара) оешмаларга, халыкара (дәүләтара) оешмалар вәкиллекләренә, халыкара (дәүләтара) оешмалар каршындагы вәкиллекләргә, шулай ук аларның Россия Федерациясе Чит эшләр министрлыгы каршында аккредитацияләнгән хезмәткәрләренә караганнарын – тиешле оешмаларның һәм физик затларның урнашу урынының адресын исәпкә алу системаларына кертеп, Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча торган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган, шулай ук вакытлыча сыеныр урын алган, качак дип танылган затларга караганнарын – чит ил гражданинының яисә гражданлыгы булмаган затның тору урынына килүе турындагы белдерүнең өзеп алына торган өлешендә күрсәтелгән адресны исәпкә алу системаларына кертеп гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча яисә даими яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга караганнарын – яшәүгә рөхсәт кәгазендә яисә вакытлыча яшәү өчен бирелгән рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән, Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны адресын исәпкә алу системаларына кертеп гамәлгә ашырыла;

чит ил юридик затларына караганнарын – чит ил юридик затларының структур

бүлекчәләренең (вәкиллекләренең, бүлекчәләренең, филиалларының) Татарстан Республикасында урнашкан урын адресларын исәпкә алу системаларына кертеп гамәлгә ашырыла.

3.6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарә, Идарә бүлеге тарафыннан белешмәләрне исәпкә алу системасына электрон рәвештә кертү юлы белән исәпкә алына һәм раслана.»;

әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында «башкарма хакимият органы» сүзләрен «башкарма орган» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Кая ______________________________________________

(үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган Россия Федерациясе субъекты башкарма органының тулы атамасы (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы))

# ГАРИЗА

Кемнән ______________________________________________

(үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспортында күрсәтелгән хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса))

| | |
|---|---|
| Тел. | ОГРНИП |
| ИНН | СНИЛС |

сорыйм ______________________________________________

(үтенечнең нигезе һәм асылы бәян ителә, үзйөрешле машинаның һәм башка төр техниканың исеме, маркасы, теркәү билгесе күрсәтелә)

______________________________________________

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

үзйөрешле машина һәм башка төр техника (алга таба — техника) паспорты:

сериясе__________________________ номеры_______________________

ОСАГО полисы

сериясе _______________________ номеры_______________________

техникага милек хокукын раслый торган документлар, ______________________

______________________________________________

техниканың уникаль электрон паспорты номеры ______________________

башка
документлар ____________________________________________
_____________________________________________________

## Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр

_____________________________________________________
(түләү йөкләмәсе (түләү турында квитанция) мөрәҗәгать итүче инициативасы белән тапшырыла)

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Документ | № | дата | «___» | ____________ | 20____ | сумма | ______________ | сум |
| Документ | № | дата | «___» | ____________ | 20____ | сумма | ______________ | сум |
| Документ | № | дата | «___» | ____________ | 20____ | сумма | ______________ | сум |

## Техника турында мәгълүматлар

Төре ____________________________________________
Маркасы, моделе, коммерция атамасы ______________________________
Завод номеры, идентификация номеры (VIN яки PIN) ____________________
Двигательнең (двигательләрнең)
моделе, номеры ______________________________
Төсе ________________ Җитештерү елы __________ Утлы маякчык ______________

## Техника төркеме турында белешмәләр

| № т/с | Төре | Марка, модель, коммерция исеме | Җитеш-терү елы | Завод номеры, идентификация номеры (VIN яки PIN) | Двигательнең (двигательләрнең) моделе, номеры | Төсе | Техниканың уникаль электрон паспорты номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

## Техника хуҗасы турында мәгълүматлар

______________________________________ Туу датасы ______________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Шәхесне таныклаучы документ ______________________________
_____________________________________________________
(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Теркәлү адресы ______________________________________
_____________________________________________________
_____________________________________________________
Телефон ____________________ Электрон почта адресы ______________

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан
_____________________________________________________
(Дәүләт техник күзәтчелек органының тулы исеме)

минем персональ белешмәләремне (эшкә сәләтле булмаган затның – персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләрен (мөрәҗәгать итүче законлы вәкил булып торган очракта) персональ белешмәләрне җыюны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, шәхси булуыннан туктатуны, таратуны (шул исәптән өченчезатларга тапшыруны), файдалана алмаслык итүне, юкка чыгаруны да кертеп), эшкәртүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге килешү мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа билгеле.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат бирү өчен субъектның элемтә өчен мәгълүматы:

______________________________________________
(почта адресы, телефон)

______________________________________________
(электрон почта адресы)

Иимза ______________________________ Дата ______________
(тулы имза)

## Милекче вәкиле турында мәгълүматлар

______________________________ Туу датасы ______________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Шәхесне таныклаучы документ ______________________________

______________________________________________
(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Яшәү урыны адресы ______________________________

______________________________________________

______________________________________________

Ышанычнамә ______________________________

Телефон ______________ Электрон почта адресы ______________

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан

______________________________________________
(Дәүләт техник күзәтчелек органының тулы исеме)

минем персональ белешмәләремне (эшкә сәләтле булмаган затның – персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләрен (мөрәҗәгать итүче законлы вәкил булып торган очракта) персональ белешмәләрне җыюны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, шәхси булуыннан туктатуны, таратуны (шул исәптән өченче затларга тапшыруны), файдалана алмаслык итүне, юкка чыгаруны да кертеп) эшкәртүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге килешү мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа билгеле.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат бирү өчен субъектның элемтә өчен мәгълүматы:

______________________________________________
(почта адресы, телефон)

______________________________________________
(электрон почта адресы)

Иимза ______________________________ Дата ______________
(тулы имза)

## Гаризаны кабул итү турында тамга

Дата «____» ________________ 20____ел.

Дәүләт техник күзәтчелек
органы дәүләт
инженер-инспекторы ______________________________ Иимза ______________

Мөһер урыны (булган очракта)

## Техниканы карау турында мәгълүмат
(мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутырыла)

Техниканы түбәндәге адрес буенча
каравыгыз турында үтенәм ________________________________

______________________________________________________________.

Техника бирүче зат ________________________________

______________________________________________________________
(дәүләт техник күзәтчелек органының дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан тутырыла)

Техника түбәндәге адрес буенча
каралачак ________________________________

______________________________________________________________.

## Техниканы карау нәтиҗәләре

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Тикшерү уздыру датасы «___» ______________ 20___ел.

Тикшерү үткәрү вакыты ________________________

Дәүләт техник күзәтчелек
органы дәүләт
инженер-инспекторы ________________________ Имза ______________

Мөһер урыны (булган очракта)

## Кабул ителгән карар турында мәгълүмат

| ТЕРКӘРГӘ<br>Дата ______________ | ИСӘПТӘН ТӨШЕРЕРГӘ<br>Дата ______________ | ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТЕРГӘ<br>Дата ______________ |
|---|---|---|
| ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕ ТУКТАТЫП ТОРЫРГА<br>______________ кадәр<br>Дата ______________ | | ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮДӘН БАШ ТАРТЫРГА<br>Дата ______________ |

## Түбәндәге документлар бирелде (рәсмиләштерелде):

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Техника паспорты (техника паспорты дубликаты) | серия | | № | |
| Техниканы теркәү турында таныклык | серия | | № | |
| «Тип 3» дәүләт теркәү билгесе | серия | | № | |
| «Тип 4А» дәүләт теркәү билгесе | серия | | № | |
| «Транзит» дәүләт теркәү билгесе | серия | | № | |
| Техниканың электрон паспорты | № | | | |

Документларны бирде

Дәүләт инженер-инспекторы
дәүләт техник
күзәтчелек органы ________________________ Имза ______________

Мөһер урыны (булган очракта)

Документларны алды

Фамилиясе, исеме, атасының исеме
(булган очракта) __________________________________________________

Дата «____» ____________________ 20____ ел. Имза ______________________

Мөһер урыны (булган очракта)»